СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
2015 елның 10 ноябре

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
№ 16

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 12 маендагы 318 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.В. Точилкинның «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң (2015 елның 12 маенда Зеленодольск шәһәре Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына (2015 елның 12 маендагы 318 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасында «2015 елда - 1,5 процент, 2016 елда - 1,8 процент, 2017 елдан - 2 процент» сүзләрен «2015 елда - 1,2 процент, 2016 елда - 1,5 процент, 2017 елда - 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соңгы елларда:» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. 2015 елның 1 декабренә кадәр әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**